| СОВЕТ ВЕРХНЕТАКЕРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ ТӘКЕРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

# КАРАР

**Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлеге составына кергән Түбән Тәкермән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2019 ел, 24 ноябрь** **№ 8**

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 17 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар түбәндәге мәсьәлә буенча җыен беркетмәсе төзелде: "2020 елда Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлегенең Түбән Тәкермән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, биш һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүчеләрдән, балачак инвалидларыннан тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?"

- Күперне реконструкцияләү (материаллар сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү)
- Янгын сүндерү гидрантын сатып алу һәм урнаштыру
- Артезиан коелары өчен насос сатып алу

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 218 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар җыенында катнашучылар саны 130 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 130 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;

“Юк” позициясе өчен _0_ җыенда катнашучы тавыш бирде.
Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлегенең Түбән Тәкермән торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – гамәлдә дип танырга.

“2020 елда Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлегенең Түбән Тәкермән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән бәлигъ булган һәр яшәүчедән (көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, биш һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүчеләрдән, балачак инвалидларыннан тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?” мәсьәләсе буенча карарны танырга һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Күперне реконструкцияләү (материаллар сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү)
- Янгын сүндерү гидрантын сатып алу һәм урнаштыру
- Артезиан коелары өчен насос сатып алу

2. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Югары Тәкермән авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, Минзәлә муниципаль районы сайтында: http://menzelinsk.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы һәм http://pravo.tatarstan Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Гамәлдәге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлегенә җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче:______________ А.Ә.Шәрипова
(имза) (тулысынча имза)

Югары Тәкермән авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе ______________ А.Ә.Шәрипова.
(имза) (тулысынча имза)